Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Клементейкино авыл Советы

КАРАРЫ

12 декабрь 2024 ел

№ 98

Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының 2007 елның 15 февралендәге 37 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлектә катнашу тәртибе турында» карарының үз көчен югалтуын тану турында.

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Клементейкино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының 2007 елның 15 февралендәге 37 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлектә катнашу тәртибе турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Клементейкино авылы, Үзәк урамы., 38 А йорт, Яңа Чишмә авылы., Гафиатуллин урамы., 3А йорт, Багряж авылы., Кызыл Йолдыз урамы, 38 А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталына» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Клементейкино авыл
җирлеге башлыгы

Л.Э. Языков